РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШЛЫГЫ

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 58
факс: 8 (84346) 2-17-57

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур.58
тел: 8 (84346) 2-10-48


# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# БОЕРЫК

2020 елның 12 мае 21№

**Район Башлыгының 2018 елның 21 декабрендәге «Әлки муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 66 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында»гы 794 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 10 октябрендәге «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль өстәмә системасы турында»гы 480 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 28 декабрендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 1934 номерлы карары, РФ Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында»гы 794 номерлы карары(2020 елның 2 апреленә үзгәрешләр белән) нигезендә һәм Әлки муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы эшчәнлеген алга таба камилләштерү максатларында Әлки муниципаль районы Башлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Район Башлыгының 2018 елның 21 декабрендәге «Әлки муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 66 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче Кушымтаның 2 пунктында «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә» сүзләрен «халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча да» сүзләргә алмаштырырга;

-4 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «муниципаль дәрәҗәдә - Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе (алга таба – районның ГТХ һәм ЯКТК)»;

-4 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «объект дәрәҗәсендә - вәкаләтләренә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләрен, шул исәптән су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итүне хәл итү дә кергән гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм оешмаларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе».;

- 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18) РСЧС ТП идарәсе белән идарә итү мәгълүмат һәм хәбәр итү сигналларын РСЧС ТП идарә һәм көчләргә җиткерүне тәэмин итә торган элемтә һәм хәбәр итү көчләре һәм чаралары, тапшырулар челтәрләре, гомуми файдаланудагы элемтә челтәре һәм ведомство элемтә челтәрләре каналлары оештыру-техник берләшмәсенең элемтә һәм хәбәр итү системаларын кулланып гамәлгә ашырыла»

-13 пунктның 3 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

- 24 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« халыкны гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә, шул исәптән ашыгыч хәбәр итү сигналларын алган вакытта гамәлләргә әзерләү;»

2. Район Башлыгының 2006 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 88 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Юсупов И.В. йөкләргә.

**Әлки муниципаль районы Башлыгы:** **Никошин А. Ф.**

Совет Алькеевского муниципального района РТ